# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
# Карамалы авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

Карамалы авылы №67 25 сентябрь 2017 ел.

Карамалы авылы җирлеге биләмәсендә
үзарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Карамалы авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Карамалы авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 26 сентябрендә чыккан 15нче номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Карамалы авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 сентябрендә чыккан 65нче номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

Карамалы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Карамалы авыл җирлеге биләмәсендә узара салым җыю һәм куллану буенча 2017нче елның 19нчы ноябрендә референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:

“Сез, Карамалы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2017 елда 250 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге бүлекләрдә укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1. Җирле әһәмияттәге автомобиль һәм җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге юлларны карау, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы белән тәэмин итү:
   - юлларның щебёнка катламын төзекләндерү

2. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү өчен (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урамнарга һәм йортларга урам исемнәре һәм йорт номерлары урнаштыруны, кечкенә архитектура формалары кую һәм карап торуны кертеп):

   - җирлектәге урам яктырту челтәрен тәртиптә тоту

- авыл җирлеге биләмәсендәге чүп үләннәрен чабу
- юлларны кардан чистарту

3. Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
   - Зират территориясен төзекләндерү (коймаларны төзәтү, территорияне чистарту, агачларны кисү һәм чыгару)

ӘЙЕ ЮК

Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.

Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: А.Р.Ногманов